**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№10097**
**28.09.2026**

«Автокаланың яшь эшмәкәре – 2026»
конкурсын әзерләү һәм үткәрү турында

Яшьләр арасында эшмәкәрлекне популярлаштыру, актив яшьләрне ачыклау һәм бүләкләү максатларында һәм Башкарма комитетның 2023 елның 2 октябрендәге 9357 номерлы Карары белән расланган «2024-2027 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасын үтәү йөзеннән

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенә Яр Чаллы шәһәрендә «Автокаланың яшь эшмәкәре – 2026» шәһәр конкурсын (алга таба – конкурс) үткәрергә.
2. Расларга:
1) конкурс турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;
2) конкурска әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.
3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны әзерләү һәм үткәрү чыгымнарын финанслауны 2026 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 112 800, 00 сум (бер йөз унике мең сигез йөз 00 тиен) күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага,  Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 28 сентябрендәге
10097 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Автокаланың яшь эшмәкәре – 2026»
конкурсы турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә Яр Чаллы шәһәрендә «Автокаланың яшь эшмәкәре – 2026» конкурсын (алга таба - конкурс) оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели. Конкурсны оештыручы булып Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе һәм «ИТ-парк» югары технологияләр өлкәсендә Казан технопаркының икенче мәйданчыгы тора.

2. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

Оештыру комитеты түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) конкурсны үткәрү тәртибен аңлата;

2) конкурста катнашучыларның заявкаларын кабул итә;

3) тәкъдим ителгән проектлар нигезендә конкурсның жюри составын формалаштыра;

4) конкурста катнашучылар исемлеген раслый;

5) конкурс финалын үткәрү көнен билгели.

2 бүлек. Конкурсның максаты һәм бурычлары

3. Конкурсның максаты булып эшмәкәрлекне яшьләр арасында нәтиҗәле тормыш стратегиясе буларак популярлаштыру тора.

4. Конкурсның бурычлары:

1) илнең икътисадый-социаль прогрессының мөһим факторы буларак яшьләр эшмәкәрлегенең уңай имиджын формалаштыру һәм популярлаштыру;

2) эшмәкәрлек эшчәнлеген алып баручы актив һәм сәләтле яшьләрне ачыклау һәм бүләкләү;

3) яшьләр арасында үрнәкләр булдыру;

4) яшьләр эшмәкәрлеген үстерү өчен шартлар тудыру, яшь эшмәкәрләр базасын формалаштыру.

3 бүлек. Конкурста катнашучылар

5. Конкурста Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче 18 яшьтән 35 яшькә кадәрге Россия Федерациясе гражданнары, шәхси эшмәкәрләр, шулай ук бер

компанияне гамәлгә куючы булып торган берничә физик зат катнаша ала. Конкурста бергә катнашучы һәм үзләренең уртак бизнесын тәкъдим итүче бер компаниянең гамәлгә куючылары булып торган физик затлар бер катнашучы буларак карала.

Конкурста катнашучы түбәндәге шартларның берсенә туры килергә тиеш:

1) шәхси эшмәкәр, оештыру-хокукый формасына һәм милек формасына бәйсез рәвештә, закон белән билгеләнгән тәртиптә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән юридик затның гамәлгә куючысы (гамәлгә куюда катнашучысы) булып торырга;

2) оештыру-хокукый формасына һәм милек формасына бәйсез рәвештә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә закон белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән юридик затның башкарма органы составына керергә;

3) үзмәшгуль булырга.

7. Конкурста катнашуга түбәндәге компанияләрне тәкъдим иткән затлар кертелми:

1) Россия Федерациясе законнары белән тыелган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы;

2) алкогольле һәм спиртлы продукция, сыра һәм аның нигезендә әзерләнгән эчемлекләр, шулай ук тәмәке, тәмәке әйберләре, тәмәке тарту кирәк-яраклары җитештерү яисә сату эшчәнлеген гамәлгә ашыручы;

3) азартлы уеннарны оештыручы яки уздыручы.

## 4 бүлек. Конкурсны үткәрү сроклары һәм тәртибе

8. Конкурс этаплап үткәрелә:

1) I этап – читтән торып. 2026 елның 28 сентябреннән 2026 елның 8 ноябренә кадәр оештыру комитетына Chelnyanp@gmail.com электрон адресына катнашучылар заявка бирәләр, белешмәләр өчен телефон – 8-951-068-00-77. Оештыру комитеты заявкаларны карый һәм II этапта катнашучыларны билгели. Заявканы караганда оештыру комитеты тапшырылган материалларның тулылыгын тикшерә. Заявка бирү срокларын бозу аны конкурста катнашудан читләштерү өчен нигез булып тора;

2) II этап – турыдан-туры. Конкурста катнашучыларның жюри әгъзаларына бизнес-проектларны ачыктан-ачык тәкъдир итүе. 2026 елның 16 ноябреннән үткәрелә;

3) финал – җиңүчеләрне игълан итү һәм бүләкләү тантанасы. Көн, II этап тәмамланганнан соң, оештыру комитеты тарафыннан билгеләнә.

## 5 бүлек. Конкурсның эчтәлеге

9. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

1) «Ел ачылышы»;

2) «Уңышлы старт»;

3) «Социаль эшмәкәрлек»;

4) «Иң яхшы ИТ СТАРТАП»;

5) «Автокала эшмәкәре».

10. Конкурста катнашуга заявка үз эченә алырга тиеш:

1) әлеге нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә катнашучының теркәлү формасын;

2) әлеге нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә теркәлү формасына кушымтаны.

## 6 бүлек. Конкурта катнашучыларны бәяләү критерийлары һәм тәртибе

11. Конкурста катнашучыларны барлык номинацияләрдә бәяләү өчен гомуми критерийлар булып тора:

1) эшмәкәрлек рухы - нәтиҗәле бизнес-идея булдыру, аны үстерү һәм тормышка ашыру, базар артыннан бару гына түгел, ә аның үзгәрү тенденцияләрен алдан күрү, стратегик һәм тактик максатлар куя һәм аларга ирешә белү сәләте;

2) идарә итү сәләте - бердәм һәм нәтиҗәле команда булдыру, хезмәткәрләрне үз идеяләре белән мавыктыру һәм аларның потенциалын ачу сәләте;

3) инновацион якын килү - яңа хезмәтләр һәм товарлар эшләүдә һәм кертүдә иҗатка һәм новаторлыкка юнәлеш бирү, компаниядә инновацияләр культурасын стимуллаштыру;

4) шәһәр өчен бизнесның социаль әһәмияте - яңа эш урыннары булдыру; хезмәткәрләрне хөрмәт итү, аларның казанышларын тану шартларын тудыру, аларның компания тормышында актив катнашуын хуплау; яшьләрне хезмәт эшчәнлеге процессына җәлеп итү, беренчел ихтыяҗ товарлары һәм хезмәтләре күрсәтү яки халыкның социаль якланмаган катламнарына юнәлеш бирү;

5) финанс күрсәткечләре - рентабельлек һәм үсеш күрсәткечләренең бизнес үсешенең тотрыклылыгын раслый торган уңай динамикасы;

6) эшмәкәр шәхесенең бөтенлеге - кыенлыкларны җиңә белү, куркынычлар белән идарә итү, билгесезлек шартларында дөрес карарлар кабул итү, дөньяга караш һәм үз-үзеңне үстерүгә сәләтлелек, хезмәткәрләр һәм конкурентлар тарафыннан танылу һәм хөрмәт.

12. Конкурста катнашучылар жюри әгъзалары тарафыннан бәяләү критерийлары нигезендә бәяләнә:

| № т/б | Критерий | Максималь бәя |
|---|---|---|
| 1. | Эшмәкәрлек рухы | 20 |
| 2. | Идарә итү сәләте | 10 |
| 3. | Инновацион якын килү | 20 |
| 4. | Шәһәр өчен бизнесның социаль әһәмияте | 20 |

| | | |
|---|---|---|
| 5. | Финанс күрсәткечләре | 10 |
| 6. | Эшмәкәр шәхесенең бөтенлеге | 20 |
| Максималь йомгаклау бәясе | | 100 |

## 7 бүлек. Конкурска йомгак ясау

13. Һәр номинациядә җиңүчеләр иң күп уртача балл җыйган катнашучылар арасыннан жюри әгъзалары тарафыннан билгеләнә. Уртача балл жюри әгъзалары тарафыннан тиешле заявкага куелган баллар суммасын әлеге заявканы караган жюри әгъзалары санына бүлеп исәпләнә. Берничә дәгъвачының уртача баллары тигез булган очракта, җиңүчеләрне сайлау жюри әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш белән үткәрелә, тавышлар тигез булганда рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

14. Жюриның эш нәтиҗәләре беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

15. Жюри эше йомгаклары буенча конкурсның бер абсолют җиңүчесе һәм һәр номинациядә берәр җиңүче билгеләнә. Җиңүчеләр дипломнар һәм акчалата призлар белән бүләкләнә: конкурсның абсолют җиңүчесе – егерме биш мең сум; номинацияләрдә җиңүчеләр – унбиш мең сум.

16. Конкурста җиңүчеләр эшмәкәрлек буенча региональ һәм бөтенроссия конкурсларында катнашырга тәкъдим ителә.

17. Конкурс җиңүчеләрен игълан итү һәм бүләкләү конкурс финалында тантаналы рәвештә үткәрелә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

«Автокаланың яшь
эшмәкәре – 2026» конкурсы
турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Катнашучының теркәлү формасы

| Конкурста катнашучы турында мәгълүматлар | |
|---|---|
| Фамилиясе, Исеме, Атасының исеме | |
| Номинация | ☐ «Ел ачылышы»;<br>☐ «Уңышлы старт»;<br>☐ «Социаль эшмәкәрлек»;<br>☐ «Иң яхшы ИТ СТАРТАП»;<br>☐ «Автокала эшмәкәре» |
| Туу датасы | |
| Вазыйфасы, эш урыны | |
| Белем (югары, урта һөнәри, урта гомуми) | |
| Тармакта, коллективта гомуми эш стажы | |
| Соңгы 3 елда хезмәт эшчәнлеге / уку:<br>кабул итү/китү ае һәм елы;<br>вазыйфасы / уку формасы;<br>оешманың исеме һәм координаталары. | |
| Өй адресы, телефон, электрон почта адресы: | |
| Паспорт мәгълүматлары (сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән, бүлекчә коды, туу урыны) | |
| Оешма турында мәгълүматлар (кулланылса) | |
| Исеме | |
| Оештыру-хокукый формасы | |
| ИНН | |
| Эшчәнлекнең төп профиле, чыгарыла торган продукция / күрсәтелә торган хезмәтләр | |
| Оешманың адресы, индексы, телефон, факс, e-mail: | |

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм ____________________
Мин «Автокаланың яшь эшмәкәре — 2026» конкурсы шартлары белән килешәм

_____________________ _________________________ ______________________________
Дата Имза Ф.И.А.и.

«Автокаланың яшь
эшмәкәре – 2026» конкурсы
турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Номинацияләр өчен теркәлү формасына кушымта эчтәлеге

| №<br>т/б | Исеме | Тәкъдим ителә торган эчтәлек |
|---|---|---|
| 1. | Катнашучы | Катнашучының эшмәкәрлек сыйфатларын, аның куркынычлар белән идарә итә белүен, билгесезлек шартларында карарлар кабул итә алуын, эш тәҗрибәсен, махсус күнекмәләрен, төп казанышларын һ.б. тасвирлагыз. |
| 2. | Бизнесны торгызу | Катнашучы компаниясенең тарихын тасвирлагыз. Компанияне төзү өчен башлангыч идеяне һәм аның яңалык дәрәҗәсен, финанс куркынычлары, катнашучы җиңгән башка җитди каршылыклар булган компанияне булдыру/эшләтеп җибәрү һәм үстерү процессының катлаулылык дәрәҗәсен тасвирлагыз. |
| 3. | Новаторлык якын килү | Катнашучының төп хезмәтләрне яки продуктларны эшләүгә һәм кертүгә иҗади һәм инновацион якын килүне ничек хуплавын тасвирлагыз. Катнашучы бизнесының уникаль үзенчәлекләре, компания һәм аның конкурентлар арасындагы төп аермалар тасвирламасын кертегез. |
| 4. | Киләчәккә планнар | Катнашучының компаниянең киләчәгенә карата кыска вакытлы һәм озак вакытлы планлаштыру күнекмәләрен күрсәтүче планнарын тасвирлагыз. |
| 5. | Бизнес белән идарә итү | Катнашучының компания белән идарә итү өлкәсендәге казанышларына, компания үсешенә ярдәм иткән стандарт булмаган һәм/яки нәтиҗәле идарә идеяләре һәм карарларына конкрет мисаллар китерегез. Компаниянең ике төп җитәкчесен (катнашучыдан тыш) тасвирлагыз, аларның эш тәҗрибәсен, махсус күнекмәләрен һәм төп казанышларын күрсәтегез. |
| 6. | Социаль җаваплылык | Компаниядәге атмосфераның хезмәткәрләрнең инициативасын күрсәтүгә, аларның һөнәри үсешенә һәм шәхси үсешенә ничек ярдәм итүен тасвирлагыз. Кушымтага компаниядә социаль климатны яхшырту буенча катнашучының инициативалары тасвирламасын, компаниянең хәйрия акцияләрендә һәм җирле һәм/яки региональ дәрәҗәдәге социаль программаларда катнашу мисалларын кертегез. |

____________________ ____________________ ____________________

Дата Имза Ф.И.А.и.